Сорау – җавап

# Нинди гамәлләр уразаның әҗер-савабын киметә?

**Солтан хәзрәт Морадыймов,**
Казанның «Рамазан» мәчете имамы:

– Сүгенү, явызлык эшләү, гөнаһлы гамәлләр кылу, әрләшү ураза тотуның бәрәкәтен, әҗер-савабын киметә. Күпләр гайбәтне гөнаһлы гамәлгә санамый. Аллаһы Тәгалә моны зур гөнаһлар рәтенә куя. Гайбәт сөйләү белән син, бу кешенең яратмаган сыйфатларын искә алып, аның дәрәҗәсен төшерәсең. Гайбәт сөйләү – кешене өстәлгә куеп, кисәк-кисәк итен ашауга тиң. Әгәр кеше гөнаһлардан тыела алмаса, безнең ач утыруыбызның хаҗәте юк.

Ә уразада икәнне белә торып ризык ашау, йә бер йотым су эчү, уразалы килеш көндез җенси якынлык кылу гыйбадәтне бозу санала.

Ураза тоту берничә өлештән тора. Ашказаны уразасы ашау-эчү мәсьәләсенә кагылса, күз уразасы хәрәм әйберләрдән күзеңне тыю, оятсыз видеолар, чит хатын-кызның гаурәт урыннарына карамау дигән сүз. Ә колак уразасы килсәк, кемдер гайбәт сөйли икән, аны сөйләүче дә, тыңлаучы да гөнаһлы. Ураза тотучының, үзенең уразалы икәнен аңлап, башка җиргә күчеп утыруы, «Алай сөйләмәгез», – дип әйтүе дә хәерле булыр. Авыз уразасы сүгенү, алдау, гайбәт, буш сүз сөйләүдән тыелу дигән сүз. Кул да начар гамәл кылмасын, аяк та начар юлга басмасын.




***

Иптәш хатыннары мактанмаса, хатын-кыз үзенә нәрсә кирәген дә белми яши.

***

– Вәли, нигә син бөтен акчаңны лотереягә әрәм итәсең? Анда оту мөмкинлеге юк диярлек бит.

– Пенсиягә кадәр исән калу ихтималы тагын да азрак, ә син пенсия взносларын тагын да күбрәк түлисең. Ә лотереядә оту мөмкинлеге бар әле.

Реклама 16+
Чаян юмор бите
chayan-journal.ru

***

Кызлар колагына: егетләр белән кибет кассасы янында танышырга кирәк. Бөтенесе дә күренеп тора: акчасы бармы, эчәргә яратамы, өйләнгәнме-юкмы. Кияүгә чыккач, «мин тегене яратмыйм, моны яратмыйм» дигән булып кыланмасын өчен дә әйбәт.

***

Ир кеше – күзләре, хатын-кыз колагы белән ярата. Шуңа күрә хатын-кызлар – бизәнә, ир кеше әкият сөйли.

***

Ирләрнең гаилә тормышы бәхетлерәк: алар соңрак никахлаша һәм тизрәк үлә.

***

Иптәш кызыма ир эзлим. Алайса аның кесәсе тулы акча, барасы килгән җирена бара, берәүдән дә сорап тормый... Психны чыгарып!

Ирләр колагына:

– Хатын эзләмәгез. Акча эшләгез, хатыныгыз сезне үзе эзләп табачак.

ВЕСТНИК ПОТРЕБИТЕЛЯ

# Сәламәт бул!

## Фитнес-клубта шөгыльләнгән вакытта кулланучылар нәрсәне истә тотарга тиеш?

**Соңгы вакытта сәламәт яшәү рәвеше алып барырга теләгән кешеләр артканнан-арта. Алар– тренажер заллары һәм фитнес-клубларның даими кунагы. Физкультура-сәламәтләндерү хезмәтләре күрсәткәндә нинди таләпләр үтәлергә тиеш?**

Башкаручы һәм кулланучы арасындагы мөнәсәбәтләр килешү нигезендә рәсмиләштерелә, аның формасы абунә, билет, чек, клуб картасы һ.б. булырга мөмкин. Түләүле хезмәт күрсәтү килешүе буенча башкаручы заказчы биреме буенча хезмәт күрсәтергә бурычлы, заказчы исә әлеге хезмәтләргә килешүдә күрсәтелгән вакытта һәм тәртиптә түләргә тиеш.

**Кулланучының түбәндәгеләргә хакы бар:**

1) мәгълүматка. «Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы РФ Законының 8 һәм 10 маддәләрендә билгеләнгән нормалар, шулай ук «Физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт хезмәтләре»нең (ГОСТ Р 52024-2003) 5.2.9 пунктлары буенча, фитнес-клубларда хезмәт күрсәткәндә башкаручы кулланучыга физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт оешмасы, күрсәтелә торган хезмәтләр турында тулы мәгълүмат бирергә бурычлы. Ул түбәндәге килешүләрне (хезмәт күрсәтүченең адресы һәм атамасы, күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге һәм бәясе, хезмәтләр алу өчен кирәкле документлар исемлеге; хезмәт күрсәтү шартлары, хезмәтләрнең тиешле төрләре өчен медицина күрсәтмәләре; физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт корылмаларында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, техник куркынычсызлык таләпләрен үтәү, спорт корылмалары территориясендә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре; штаттан тыш хәлләрдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре; гомуми файдаланудагы урыннар һәм медицина ярдәме пунктлары; хезмәт күрсәтүче персонал квалификациясе) төзегән вакытта кулланучыга ачык һәм үтемле формада җиткерелә.
2) фитнес-клуб хезмәтләреннән баш тарту. Кулланучының башкаручы әлеге килешү (РФ Законының 32 маддәсе) буенча ул сарыф иткән чыгымнарны түләү шарты белән теләсә кайсы вакытта хезмәт күрсәтү турындагы килешүне үтәүдән баш тартырга хакы бар. Шул ук вакытта, ул күрсәтелмәгән хезмәтләр өчен акчаны кире кайтаруларына исәп тота ала. Әгәр хезмәт күрсәтелгән икән, башкаручы килешүнең үтәлүенә бәйле рәвештә аның чыгымнарын каплый торган суммага өметләнергә хокуклы. Кулланучы гаебе (фитнес-клубка килми калу) белән килешүне үтәп булмаган очракта хезмәтләр өчен тулы күләмдә түләргә туры киләчәк, башкаручының акчаны кире кайтармаска хакы бар (РФ Гражданнар кодексының 781 маддәсе 2 өлеше).
3) хезмәтнең куркынычсызлыгына. РФ Законының 7 маддәсе нигезендә, фитнес-клубларда спорт хезмәтләре һәм кулланучыларга хезмәт күрсәтү шартлары тормышка, сәламәтлеккә, кулланучыларның милкенә һәм әйләнә-тирә мохиткә куркыныч тудырмаска тиеш.
4) хезмәт күрсәтү сроклары. Әгәр килешү төзелгән һәм фитнес-клуб хезмәт күрсәтми, ә хезмәт күрсәтү сроклары билгесез һәм килешүдә күрсәтелмәгән икән, кулланучының килешүдән баш тартырга һәм акчаны кире кайтаруны таләп итәргә хакы бар. Хезмәт күрсәтү срокларын бозган өчен башкаручы бәянең 3 проценты күләмендә штраф түләргә, матди һәм әхлакый зыянны компенсацияләргә бурычлы.

# Турист, кешбэктан файдаланып кал!

**Яз – сәяхәт итү өчен иң кулай вакыт. Быел Россиядә курорт сезоны 1 майда ачыла. Россия туристларының май бәйрәмнәрендә һәм җәй башында янә арзанрак бәягә ял итү мөмкинлеге барлыкка килде – туристик кешбэкның чираттагы этабы башланды. 15 июньгә кадәр кешбэк белән юлламалар сатып алырга, шул ук вакытта 30 июньгә кадәр сәфәр чыгарга мөмкин.**




Программада катнашу шартлары моннан алдагы ике этаптагы *кебек үк:*

- ✔ *турның озынлыгы яки кунакханәдә яшәү вакыты 2 төннән дә ким тәшкил итмәскә тиеш;*
- ✔ *туристның картасына юллама яки кунакханәдә яшәү өчен түләгән акчаның 20 проценты кире кайтачак, бу күп дигәндә 20 мең сум дигән сүз;*
- ✔ *юллама бәясен МИР карточкасы белән түләргә, Россиянең теләсә кайсы төбәгенә сәфәр чыгарга мөмкин.*

**Программада 3,5 меңгә якын кунакханә һәм туроператор, шулай ук хезмәт күрсәтү агрегаторлары катнаша. Туристлык хезмәтләрен мирпутешествий. рф сайтында һәм программа партнерларының сайтларында сатып алу мөмкинлеге бар.**

Краснодар краенда һәм Кырымда инде җәй хакимлек итә, язгы чорда Кавказдагы Минеральные Воды, Адыгея Республикасы, Алтай, Төмән, Башкортстан һәм Удмуртия, Балтыйк буенда – Калининград һәм Санкт-Петербургның курорт районы кебек маршрутлар аеруча актуаль.

Апрель-май айларының соңгы көннәрендә елга навигациясе ачыла — Идел елгасы буйлап сәяхәтләр башлана. Себердә һәм Ерак Көнчыгышта табигатьтә актив ял итү өчен турлар формалаша, Домбай һәм Архызда тау чаңгысы сезоны дәвам итә, ә Себердәге Шерегеш курортында май башына кадәр чаңгы шуарга мөмкин.

Программа ял көннәрендә бөтен гаилә белән илнең теләсә кайсы төбәгенә кыска вакытлы сәяхәтләр өчен киң сайлау мөмкинлеге тәкъдим итә. Бу – Мәскәү яки Санкт-Петербургка сәяхәтләр, Татарстан Республикасы, Түбән Новгород, Воронеж, Алтын Боҗрага кергән тарихи шәһәрләр, Төньяк Кавказ төбәкләре буйлап экскурсия маршрутлары булырга мөмкин. Язгы чор – хис-кичерешләргә бай вакыт: әйтик, апрель урталарында Калмыкиядә – лаләләр, ә май аенда Алтайда маральник («Себер сакурасы») чәчәк ата. Аның матурлыгына бары тик Россиядә генә сокланырга мөмкин.

АТНА ВАКЫЙГАЛАРЫ
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Татар–информ» мәгълүмат агентлыгында әзерләнде.

Генераль директор – Шамил Мөхәммәт улы Садыйков.
Баш редактор – Рәмис Нурмөхәммәт улы Латыйпов.
Җаваплы редактор – Лилия Гаделшина.
Дизайн–верстка – Светлана Щеглова.
Корректор – Раис Габдуллин.

Тел.: (843) 222–09–83 (1304; 1414)
Редакция һәм нәшир адресы:
420066, Казан ш., Декабристлар ур., 2нче йорт.
Эл.адрес: info@tatar–inform.tatar
Реклама хезмәте телефоны: (843) 570–31–07

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсендә Федераль күзәтчелек хезмәтенең (РОСКОМНАДЗОР) Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2014 елның 9 гыйнварында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы: ПИ №ТУ16–01140
Басмага бирү вакыты: 21 апрель 2021, график буенча – 24.00, гамәлдә – 24.00

ТАТМЕДИА Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ

Нәшир адресы:
420097, Казан ш., Академия ур., 2
**Басылу урыны:**
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел–Пресс» полиграфия–нәшрият комплексы.,
Казан ш., Декабристлар ур., 2
Тираж –64 056 экз.
**Гомуми тираж: 64 056 экз.**

Редакция фикере автор фикере белән туры килмәскә мөмкин. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Реклама игъланнарының дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
© Язмаларны күчереп бастыру фәкать редакция рөхсәте белән генә башкарылырга тиеш. Газета атна саен чыга. Бәясе ирекле.
*«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла*
16+